Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Екатериновка авыл җирлеге башкарма комитеты

Екатериновка авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАРЫ

31 май, 2024 ел № 13

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 27 июлендәге 9 номерлы карары белән расланган салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенең 4 һәм 5 пунктларына туры китереп Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Екатериновка авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген (кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Екатериновка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Екатериновка авыл җирлеге башлыгы А.Н. Жуков